**Татарстан Республикасы Зәй  муниципаль районы**
**Иске Маврин авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 103** **12.05.2023 ел**

**Җирле салымнар суммасы өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Җирле салымнар суммасы өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның үлеменнән яки аны граждан-процессуаль законнарда билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан иткән көннән соң өч ел вакыт узу, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, я варисларның берсе дә мираска хокукка ия булмаса яки барлык варислар да варислыктан читләштерелсә, йә мирасны берәү дә кабул итмәсә, йә барлык варислар мирастан баш тартса, шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәсә;

2) салым түләүче-физик затның гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы;

3) салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән алып өч ел срок тәмамлану;

4) җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч ел срок тәмамлану.

2. Үз көчен югалткан дип таныргa:

2.1. «Җирле салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча недоимкаларны һәм бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» 2020 елның 10  декабрендәге 18 номерлы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советы карарын;

2.2. «Җирле салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча недоимкаларны

һәм бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» 2020 елның 10 декабрендәге 18 номерлы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында" 2022 елның 29 декабрендәге 90 номерлы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советы карарын;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлек торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе** **Р.Г.Нургалеев**